**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 334 . 14.10.2022

**«Апас муниципаль районы территориясендә торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия турында» карарына үзгәреш кертү хакында**

"Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 28 сентябрендәге 1708 номерлы РФ Хөкүмәте карарына таянып, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2020елның 10 декабрендәге 394 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы территориясендә торак фондының торак урыннарын бәяләү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне, 2.3 пунктында «янгын сүндерү» сүзен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары А.М. Хәсәновка йөкләргә.

**Җитәкче** **А. А. Тугушев**